**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 август № 610

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 31 июль, 533 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче, 2015 ел, 02 февраль, 49 нчы, 2015 ел, 3 июнь, 401 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 нче пункт үз көчен югалаткан дип танырга;

1.5 нче пунктта «турыдан-туры яки үзләренең территориаль органнары аша» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3 нче пунктта:

3.3.1 нчы пунктчасының унберенче абзацына «, шулай ук табигатьне саклау законнары үтәлешен тәэмин итү максатларында эшчәнлек өлкәсендә билгеләнгән бүтән таләпләр белән» сүзләрен өстәргә;

3.3.6 нчы пунктчасының бишенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары гамәлгә ашырган дәүләт экологик контроленә» сүзләрен «төбәк дәүләт экологик күзәтчелегенә» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.13 нче пунктчасында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.13. Министрлык эшчәнлеген тәэмин итү өлкәсендә:»;

унынчы абзацны төшереп калдырырга;

5.2 нче пунктта:

бишенче абзацта «, Министрлыкның территориаль органнарын» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацта «һәм аның территориаль органнарын» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.3 нче пунктның беренче абзацында «, аның территориаль органнарын һәм Министрлык карамагындагы оешмаларны» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Үз көчен югалаткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 9 июнь, 454 нче карарының 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларны һәм 2 пунктын;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2011 ел, 13 апрель, 291 нче карарының икенче абзацын;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында»2012 ел, 30 июль, 646 нчы карарының 1 пунктындагы икенче абзацны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\610.docx